ГЛАВА
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.04.2024 с.Старое Дрожжаное № 8

«Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы каршындагы тәрбия эше буенча, Татарстан Республикасының балалар һәм яшьләрнең «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәтенең төбәк бүлекчәсен үстерү, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре белән үзара хезмәттәшлек итү буенча Советы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы каршындагы тәрбия эше буенча, Татарстан Республикасының балалар һәм яшьләрнең «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәтенең төбәк бүлекчәсен үстерү, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре белән үзара хезмәттәшлек итү буенча Советы турында» 2023 елның 28 декабрендәге 59 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле **4 пункт өстәргә:**

«4. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы каршындагы тәрбия эше буенча, Татарстан Республикасының балалар һәм яшьләрнең «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәтенең төбәк бүлекчәсен үстерү, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре белән үзара хезмәттәшлек итү буенча Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы буенча Россия балалары һәм яшьләре хәрәкәтенең җирле бүлекчәсе (РДДМ) җитәкчесен, сәркатибен Багаутдинова Венера Айрат кызын штаттан тыш нигездә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы ярдәмчесе статусы белән йөкләргә.»;

**4,5 пунктларны** тиешенчә **5,6 пунктлар** дип санарга;

1 нче кушымта белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы каршындагы тәрбия эше буенча, Татарстан

Республикасының балалар һәм яшьләрнең «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәтенең төбәк бүлекчәсен үстерү, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре белән үзара хезмәттәшлек итү буенча советының составына «Гәрәева Венера Айрат кызы» сүзен «Багаутдинова Венера Айрат кызы» сүзләре белән алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетына йөкләргә.

Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы М.Р. Гафаров